КИЛЕШЕНГӘН
Әтнә муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесе
_______________ А.Ф.Каюмов
«15» «ноябрь» 2024 ел

КИЛЕШЕНГӘН
Әтнә муниципаль районы
башкарма комитеты
мәдәният бүлеге җитәкчесе
_______________ А.Р.Абдуллина
«15» «ноябрь» 2024 ел

КИЛЕШЕНГӘН
Әтнә муниципаль районы
башкарма комитеты
мәгариф бүлеге җитәкчесе
_______________ Р.Р.Фатыхов
«15» «ноябрь» 2024 ел

РАСЛЫЙМ
Әтнә муниципаль районы
башкарма комитеты
"Әтнә туган якны өйрәнү
музее" директоры
_______________ Э.И.Мөхәммәтҗанова
«15» «ноябрь» 2024 ел

# Сибгат Хәкимнең тууына 113 ел тулу уңаеннан

# «Сибгат чишмәсе»

## республикакүләм әдәби шигырь укучылар бәйгесе

## нигезләмәсе

**1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР**

1.1. Әлеге Нигезләмә «Сибгат чишмәсе» республикакүләм әдәби шигырь укучылар бәйгесе (алга таба – Конкурс) максатларын, бурычларын, шартларын һәм тәртибен билгели.
1.2. Бәйге Сибгат Хәким тормышы һәм иҗаты белән кызыксынучы шигырь сөючеләр арасында үткәрелә.

**2. БӘЙГЕНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ**

2.1. Бәйге сөйләм телен үстерү һәм нәфис сүз белән кызыксынуны формалаштыру, шигъри сүзнең матурлыгын һәм чагылышын тою максатыннан үткәрелә.
2.2. Бәйгенең бурычлары:

- татар телен һәм мәдәниятен алга этәрү, саклау һәм үстерү;
- Сибгат Хәкимнең иҗади мирасын популярлаштыру, иҗатына кызыксыну арттыру;
- өлкән һәм яшь буынны татар халкының милли гореф - гадәтләренә җәлеп итү;
- талантлы нәфис сүз осталарын ачыклау, аларга үз-үзләрен күрсәтү өчен мөмкинлекләр бирү;
- сәнгать һәм башкару осталыгын арттыру өчен шартлар тудыру;
- әдәби шигъри әсәрләргә уңай эмоциональ мөнәсәбәт тәрбияләү.

**3. БӘЙГЕНЕ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ**

3.1. Бәйгене оештыручылар:
• *Әтнә районы башкарма комитеты;*

• ***Әтнә мәдәният бүлеге;***
• ***Әтнә мәгариф бүлеге;***
• ***"Әтнә туган якны өйрәнү" музее.***

3.2. Бәйгенең оештыру комитеты бәйге әгъзаларын раслый.

4. **БӘЙГЕДӘ КАТНАШУЧЫЛАР**

- өлкән буын;
- урта яшьтәге катнашучылар;
- мәктәп укучылары;
- профессиональ артистлар.

**4. БӘЙГЕ НОМИНАЦИЯЛӘРЕ**

4.1. Бәйге түбәндәге номинацияләрдә билгеләнә:

- Сибгат Хәким әсәрен татар телендә башкару;
- Сибгат Хәким әсәрен рус телендә башкару;
- Сибгат Хәким әсәрен дөнья телләрендә башкару;
- Сибгат Хәкимнең фронт - поэзиясе;
- Сибгат Хәкимнең туган як шигърияте.

Сибгат Хәкимнең бер әсәре (тулысынча яки өзек) татар телендә, рус телендә, дөнья телләрендә тәкъдим ителергә мөмкин. Шулай ук Сибгат Хәким турында катнашучының үзе язган бер әсәрне (шигырь, поэма, эссе) сөйләргә мөмкин. Үтәлү вакыты – 3 минуттан артмау мөһим.

**5. БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ**

* башкару осталыгы;
* әсәрне яшь категориясе буенча сайлау;
* әсәрнең образлыгы һәм мәгънәлелеге, үтеп керү тирәнлеге;
* чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар кулланылырга мөмкин;
* музыка белән тәэмин итү, декорацияләр һәм костюмнарны куллану чыгыш ясаган өчен баллар ясаганда исәпкә алынмый һәм рекомендация булып тормый;
* конкурсның һәр катнашучысы мөстәкыйль рәвештә чыгыш ясый һәм чыгыш ясаган вакытта башка затлар ярдәменә таяна алмый.
* теманы ачу тулылыгы, әсәрнең композициясе, стилистик үзенчәлекләре, бәян итү логикасы, оригинальлек, әдәби жанр үзенчәлекләрен белү һәм куллану, шигырьләр законнарын белү һәм куллану.

**6. БӘЙГЕНЕ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ**

6.1. Конкурста катнашу бушлай.
6.2. Катнашучыларның яше 7 яшьтән башлана.
6.3. Яшь төркемнәре һәм категорияләре конкурс номинацияләрендә:

- *7 яшьтән 12 яшькә кадәр (кертеп);*
- *13 яшьтән 18 яшькә кадәр (кертеп);*

- ✓ *19 яшьтән 30 яшькә кадәр (кертеп);*
- ✓ *31 яшьтән һәм олкәнрәк.*

6.4. Бәйгедә катнашучылар билгеләнгән көнне, билгеләнгән урында чыгыш ясыйлар.
6.5. Катнашучыларның нигезләмәдә бирелгән гаризаны (Форма 1) тутырулары зарур. Әлеге гаризалар ***2024 елның 30 ноябренә*** кадәр кабул ителә.
6.6. Гаризалар **sibgat.chishmese@mail.ru** почтасына җибәрелү мөһим.
6.7. Бәйге 4 этапта үткәрелә:

**1 нче этап – беренче сайлап алу туры:**
*Әлеге турда ерак һәм якын районнар катнашучылары чыгыш ясый. Сезне 2 декабрь көнне сәг. 10.00 дә Күлле Киме авылы мәдәният йортында көтеп калабыз.*

**2 нче этап – икенче сайлап алу туры:**
*Әлеге турда Әтнә районы катнашучылары чыгыш ясый. Сезне 5 декабрь көнне сәг. 10.00 дә Күлле Киме авылы мәдәният йортында көтеп калабыз.*

**3 нче этап – өченче сайлап алу туры:**
*Әлеге турда профессиональ артистлар чыгыш ясый. Сезне 6 декабрь көнне сәг. 10.00 дә Күлле Киме авылы мәдәният йортында көтеп калабыз.*

**4 нче этап – финал һәм бүләкләү өлеше:**
***Финал 2024 елның 10 декабре көнне Күлле Киме авылы Сибгат Хәким музеенда үткәрелә.***

**7. КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БҮЛӘКЛӘҮ**

Бәйге нәтиҗәләре буенча, жюри урыннар билгели.

- Лауреат I, II, III урын;
- Гран – при;
- Махсус бүләк "Профессионал"

***Барлык сораулар буенча 2-19-57, 89274021465 номерларына шалтыратырга мөмкин.***

***Һәр яңалыкны яки үзгәрешне ВКонтакте (Мбук Атнинский-Районный-Краеведческий) битләрендә яки Телеграмм каналда (Атнинский районный краеведческий музей) күзәтергә мөмкин.***

Форма 1

**Гариза**

***Катнашучының ФИО*** ________________________________________________

*Туган елы, коне, ае (яшь торкеме)*__________________________________

*Яшәү урыны*_________________________________________________________

*Номинациясе*________________________________________________________

*Башкарылачак әсәрнең исеме*_________________________________________

*Оешма исеме*________________________________________________________

***Җитәкчесенең ФИО***_______________________________________________

*Телефон (катнашучы яки җитәкче)*____________________________________